Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская д. 66 в, с. Кавзияково
423377
Телефон: 8 85559 4-47-16

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЭУЖИЯК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 66в йорты,Кэужияк авылы,
423377
Телефон:: 8 85559 4-47-16

ОГРН 1061687002992 ИНН/КПП 1636005503/163601001 ОКАТО 92253824000

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 15 сентябре № 8

Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Башкарма комитетының 26.12.2015 ел, № 12 карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 14.07.2022 ел, № 312-ФЗ Федераль закон нигезендә, Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган 26.12.2015 ел, №12 муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктында «(1 нче кушымта) " сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган 26.12.2015 ел, №12 муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулардан башка арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1.2 пунктында «(1 нче кушымта) " сүзләрен төшереп калдырырга;

1 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

3. 2 нче кушымтаның 2 нче бүлегендәге 2.9 пунктындагы 13 пунктчасында 4-16, 28 «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару»сүзләренә алмаштырырга.

4 Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы» һәм https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ф.Ә. Хөснетдинов